**ГЛАВА МЕМДЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422728, Республика Татарстан, Высокогорский район,, с.Мемдель, ул.Кооперативная, 30

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМДӘЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422728, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мәмдәл авылы, Кооператив ур.,30

Тел./факс: +7(84365) 60-2-37, e-mail: Memdel.Vsg@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**19 октябрь 2022 ел** **№ 3**

# Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Юртыш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 23 октябрендәге 162 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Юртыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 31 октябрендә 17.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча: Юртыш ав., Кооператив ур., 34а й. (Юртыш авыл клубы) билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2023 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Юртыш торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- су басуга каршы дамба төзу
- тракторга өстәмә җиһазлар
- урам яктырткычлары алу

белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Сафиуллин